**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2438**
**26.05.2020**

Яр Чаллы шәһәренең «Заман» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 пунктның 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Заман» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 26 маендагы
2438 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Заман» яшьләр үзәге»
муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан
күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәя |
|---|---|---|---|
| I. Балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең мәшгульлеген оештыру буенча хезмәтләр | | | |
| 1. | Бию клубы (кеше) | 1 дәрес | 200,00 |
| 2. | Көнчыгыш биюләре (кеше) | 1 дәрес | 200,00 |
| 3. | Вокаль клуб (кеше/төркем белән) | 1 дәрес | 200,00 |
| 4. | Вокаль клуб (кеше/индивидуаль) | 1 дәрес | 300,00 |
| 5. | Психологик-педагогик консультация | 1 дәрес | 350,00 |
| 6. | Психологик-педагогик диагностика | 1 дәрес | 500,00 |
| 7. | Йога сөючеләр клубы (кеше) | 1 дәрес | 200,00 |
| 8. | Инглиз теле клубы (кеше) | 1 дәрес | 300,00 |
| 9. | Балалар үсеш клубы (кеше) | 1 дәрес | 500,00 |
| 10. | Бокс, самбо (кеше) | 1 дәрес | 200,00 |
| 11. | Балалар сәнгать иҗаты клубы (кеше) | 1 дәрес | 200,00 |
| 12. | Имидж клубы (кеше) | 1 дәрес | 400,00 |
| 13. | Кызыксыну буенча клуб (кеше) | 1 дәрес | 100,00 |
| 14. | Фитнес-клуб | 1 дәрес | 200,00 |
| 15. | Озайтылган көн клубы | 1 дәрес | 200,00 |
| 16. | Спидкубинг | 1 дәрес | 200,00 |
| II. Чаралар үткәрү буенча хезмәтләр | | | |
| 1. | Бәйрәм программасы (кеше) | 1 программа | 300,00 |
| 2. | Балалар уен программасы, дискотека (кеше) | 1 программа | 200,00 |
| 3. | Иҗат буенча мастер класс | 1 дәрес | 150,00 |
| 4. | Тематик квест | 1 дәрес | 250,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова